**Р. Шаһиева,**
**Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе**

# ЖИРСҮ

Шома балчык өстендәге бөгем-бөгем сырларга орыныр-орынмас тиеп үткән балкыш нурымы бу? Әллә көмешсу бизәкләрдән саркыймы ул моңлы авазлар?

Әлеге сыннарга карауга, балачак искә төшә: иснәргә-сыйпарга өлгермәгән чәчәк-башаклар, хәтердә сакланган рәхәт күләгәләр, мөлдерәмә сулы күлләр, туздырылмыйча калган бака хәтфәсенең йомшаклыгы, ана күкрәгедәй калку җиләкле түмгәкләр артына поскан шомлы-сискәндергеч бөҗәк-камкалар... Таҗлы балык, канатлы кара елан, адашып чыелдаган Сак-Сок тавышлары – болар һәммәсе балачактан әкият булып җаннарга сеңгән бит!

Чылтыраган чишмә тавышларын, асылташларның нурлы җемелдәвен, ягымлы-тансык балачак хыялларын Хәмит ничек кайтара ала икән? Бәлки, яшьли дөнья куйган газиз әнкәсен сагыну моңлы итәдер аны? Кем белә, бәлки, балачагында укыган, ишеткән әкиятләрне, күңелгә нәни вакыттан сеңгән образларны сыннар итеп әвәләү аңа югалган балачагын сагынып, аны озайтырга теләү өчен кирәктер! Аның рәхмәте дә, хис-уйлары да балчыктан әвәләнгән шул сыннарга күчә, ул аларны кабат халыкка кайтара – инде касәләр, әкияти образлар, кызыклы-могҗизалы сәнгать әсәрләре итеп!

Рәссам Хәмит Латыповның иҗатында аңа образы, хатын-кыз сурәтләре гаҗәеп кызыклы, үзенчәлекле итеп сурәтләнә. Аның иҗатында төп урынны мифик образлар – кәкре-бөкре муенлы үрдәк, каз сыннары, ялан тәпиләре белән тыпырдашып торган, ярканат башлы, гәүдәсе шүрәлегә охшаш, авыл малайларының протатибы дип әйтерлек затлар били икән - моңа да гаҗәпләнәсе юк, чөнки рәссам дөньяны әкияти геройлар аша күрә.

Балачак күзләре белән серле әкият дөньясына бага һәм шундый кызыклы образлар тудыра ки, моңа инде сокланмый калу мөмкин дә түгел! Алар төрле төскә, төрле сурәткә керә ала, әмма куркыныч түгел. Чөнки торaташ булып каткан балчык сыннар – әкият бит!

Хәмитнең балачак хыялларымы бу, ятимлек-үксезлеген оныттырган, үзе уйлап чыгарган, аның күзенә күренгән образлармы? Алар аны юатып-юмалагандыр, канатландырган һәм адаштыргандыр! Бу мифик образларның кош булып сайрауларын ул бәлки халык җырлары аша тойгандыр.

Сынчы үзе дә бик моңлы, матур итеп җырлый, сайрар кошлар – сандугачлар сыман хыялында талпына. Татар халык көйләренең моңы күкрәкләрдән гөрелдәп чыккан сыман. Хәмитнең күңел түрендә йөргән, ургылып тышка чыга алмаган шул аһәңнәре дә аның җанын бимазалап торган әкияти затларны гүзәл чүлмәк сәнгатенә – керамикага күчерергә ярдәм иткәндер.

Әнә, шәмдәлне генә алып карыйк. Шыксыз, ямьсез Шүрәлене дә “Гөлҗамал”ларны җырлаганда шәм булып янарлык шәм савытына әверелдерелгән бит! Озын кулларын ике якка борып, шәм куясы касәләрне тоткан, мөгезләре колак белән тоташып, тоткычка әйләнгән дә, баштүбәсенә утлар кабызу өчен өченче касә – болгар чeрагларын – яктырткычларын хәтерләткән савыт – керамик композиция хасил булган. Көнкүреш әйберләрен хайваннарга, аларның гәүдә торышларына охшатып ясау – болгар осталарыннан калган ысул. Ул балчык савытларга җан өргән, серле кәмитлек, форма үзгәлеге өстәгән. Әмма шул ук вакытта заманча чишелеш тапкан – авангардизм юнәлешенә күз токан гүзәл әсәрләре белән нурланып, җанланып китте. Яшәешнең “догасын” сурәтләүче, галәмнең салкын авазларын сыйдырган бу композицияләр Шнутке, Софья Гобәйдуллина музыкасы, андагы чыңнар белән аваздаш итеп кабул ителә.

Останың эзләнүләр диапозоны да шактый киң: яңа гына татар керамикасына килеп кергән “кара төс”, балчык эшләнмәләргә – данлыклы Иран керамикасын хәтерләткән көмеш сеңдермәләр кертү, татар халык иҗатыннан – уенчык-сыбызгылар, ювелир әсәрләреннән кергән бәйрәмчә тантаналы бай төсләр гаммасы, фән-техника чорына караган кырыс ысыллар – дизайн чагылышы, авангардизм серләре – болар барысы да Хәмит әсәрләренә образ тема ягыннан гына түгел, форма, фактура буенча да үзгәртүләр кертте, баетты. Шуларның барысын да бергә туплаган, берләштергән гаҗәеп күпкырлы, тирән мәгънәле, киң форматлы сәнгать пәйда булды.

Балчык эшендә ялгышулар кичерелми, чөнки нәрсәседер ашык-пошык кына әвәләнсә, утта янган чакта, ул кубып төшә, ярыла, юкка чыга. Хәмит моны бик яхшы үзләштергән, ул һәр нәрсәдә тугрылыклы, ачыклыкны, дөреслекне сөя.

Хәмитнең изге максаты татар сәнгатенә, мәдәниятенә хезмәт итү. Шуңа күрә кул кушырып утыра алмый, ул эштә, хәрәкәттә, ул тудырган образлар да мәңгелек хәрәкәттә...

Бәлки, шуңадыр, аның әсәрләре якты, кояшлы...

*// Сөембикә. – 1994. – № 4*